| | |
|---|---|
| **СОВЕТ СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ-ТӘРБИТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

РЕШЕНИЕ КАРАР

03 сентябрь 2020 ел. Иске-Тәрбит авылы №15

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Кушымта итеп бирелә торган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Кайбыч муниципаль районы
Иске-Тәрбит авыл җирлеге
Башлыгы В.Г.Тимофеев

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл жирлеге Советының 03.09.2020ел. 15 номерлы карарына кушымта

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең жирле үзидарә органнары һәм «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең жирле үзидарә органнары арасында жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе

1. Әлеге «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл жирлеге (алга таба - Поселение) һәм «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең жирле үзидарә органнары (алга таба - Район) арасында жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе «Россия Федерациясендә жирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - «Россия Федерациясендә жирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон) нигезендә эшләнгән.

2. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Җирлек бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында Районның жирле үзидарә органнары белән килешүләр төзергә хокуклы.

Шул ук вакытта районның жирле үзидарә органнары жирлек территориясендә авыл жирлегенең жирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча районның жирле үзидарә органнарына аерым вәкаләтләр бирү турындагы килешүләр нигезендә гамәлгә ашыра.

3. Жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Жирлек вәкаләтләренең бер өлешен Районга тапшыру өчен Жирлек Советы Жирлек вәкаләтләренең бер өлешен аларга тапшыру турындагы тәкъдим белән Район советына мөрәҗәгать итә.

4. Вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру мәсьәләләре район Советы һәм Җирлек Советы утырышларында карала һәм карарлар рәвешендә рәсмиләштерелә.

5. Жирлек Советы Районның жирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карарны Районның жирле үзидарә органнарына карауга җибәрә.

6. Район Советы Җирлек Советы карарын уңай карау нәтиҗәсендә Җирлек жирле үзидарә органнары белән Район жирле үзидарә органнары арасында килешү төзи.

Күрсәтелгән килешү билгеле бер срокка төзелергә, аның гамәлдә булуын туктату нигезләрен һәм тәртибен билгели торган нигезләмәләрне, шул исәптән вакытыннан алда, тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларның еллык күләмен билгеләү тәртибен, шулай ук килешүләрне үтәмәгән өчен финанс санкцияләрен күздә тотарга тиеш.

Килешү проектын эшләү өчен, һәр яктан бертигез санда вәкилләр кертелеп, эш төркеме төзелергә мөмкин. Эш төркеме үз эше нәтиҗәләре буенча килешү проектын әзерли, ул ике якның мәнфәгатьләрен максималь исәпкә ала.

Килешү районның жирле үзидарә органнары һәм аны муниципаль берәмлек уставы нигезендә бастырып чыгарган мизгелдән соң жирлек өчен үз көченә керә һәм мәҗбүри була.

7. Җирлек Советы районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы карар проектын кире каккан очракта, Район Советына алар башлап җибәргән мәсьәләне карау нәтиҗәләре турында хат җибәрелә.

8. Килешүдә каралган вәкаләтләрне үтәү өчен кирәкле финанс чаралары бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.

Бюджетара трансфертларны максатчан файдаланмаган очракта, алар Җирлек бюджетына ун көн эчендә кайтарылырга тиеш.

Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларны тапшыру максатларында бюджет законнары нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга кирәкле акчалар каралган район һәм Җирлек бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертелә.

Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга Җирлек бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертларны формалаштыру, санап чыгару һәм исәпкә алу Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары ай саен тигез өлешләр яисә бер үк вакытта финанс чараларының бөтен суммалары белән күчерелә.

9. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен кирәк булганда, муниципаль мөлкәт түләүсез срокլы файдалану шартнамәсе нигезендә тапшырыла, ул килешү гамәлдә булу чорына төзелә.

10. Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җирлек советы карары белән каралган очракларда һәм тәртиптә үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдаланырга хокуклы.

11.Вәкаләтләрне тапшырган җирлекнең җирле үзидарә органы тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, тапшырылган финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында кирәкле мәгълүматны соратып ала.

12.Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Җирлек файдаланылмаган финанс чараларын һәм матди ресурсларны һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган мөлкәтне кире кайтара.

13. Төзелгән килешүне үтәүгә бәйле бәхәсләр сөйләшүләр уздыру һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә. Бәхәсне сөйләшүләр уздыру яки килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул кануннарда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш.

14.